КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 апрель г.Казань № 257

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 17 октябрь, 1104 нче карары белән расланган «Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының һәм «Этилен-600» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 17 октябрь, 1104 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 декабрь, 1475 нче; 2023 ел, 18 апрель, 487 нче; 2023 ел, 19 декабрь, 1638 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм

процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының һәм «Этилен-600» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә субсидияләр бирү тәртибенә, 4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4.2 Вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Тәртипнең алтынчы – сигезенче, унынчы – ундүртенче пункларында күрсәтелгән документлар тапшырылганнан соң, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы 10 эш көне эчендә аларны тикшерә һәм, тикшерү үткәргәннән соң, ике эш көне эчендә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алган проект (смета) документларына әлеге тапшырылган документларның туры килүе яисә туры килмәве турындагы бәяләмәне Вәкаләтле органга җибәрә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин